Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе
"Югары Әлморза төп гомуми белем мәктәбе"

РАСЛЫЙМ
Мәктәп директоры
Нутфуллина Ф.З.

# Югары Әлморза мәктәбе китапханәсенең 2022 – 2023 нче уку елына еллык эш планы

**Китапханәче**: Сагдатшина Ә.М.

## ***2021 – 2022 НЧЕ УКУ ЕЛЫНА АНАЛИЗ***

Мәктәпне китапханәсез күз алдына китерүе кыен. Мәктәп китапханәсе һәр укучы һәм укытучының төп таяну ноктасы булып тора. Белешмә сүзлекләр, методик ярдәмлекләр, матур әдәбият, вакытлы матбугат чаралары - һәммәсе бүгенге укучыга багышлана.

Китапханә ул - мәктәп терәге, ә мәктәп - белем йорты. Мәктәп китапханәсе укучыларны белемле итүдә зур роль уйный. Белемнең күп өлешен укучы үзлегеннән китаплардан ала.

2021 – 2022 нче уку елында китапханә үзенең эшенә түбәндәге бурычларны куйды:

- мәктәп китапханәсенең эшен укыту-тәрбия планына нигезләнеп укучыларга эстетик тәрбия бирү юнәлешендә оештыру;
- укучыларның китапханәгә даими йөрүләренә ирешү;
- укучыларда китап уку культурасы тәрбияләү;
- укучыларда китапханә китапларына сакчыл караш тәрбияләү.

Китапханә укучылырга, укытучыларга һәм башка төр хезмәткәрләргә ачык типта һәм бушлай хезмәт күрсәтә. Китапханә үз эченә күп кырлы фондны ала: дәреслекләр, әдәби китап, справочниклар, фәнни – популяр әдәбият, укучылар өчен, шулай ук укытучылар өчен һ.б. өчен вакытлы матбугат материаллары. Китапханәдә китаплар ачык фонд буенча куелган. Китаплар фонды алфавит тәртибендә урнашкан. Китапханәнең уку залы юк, укучы китапларны үзе сайлап ала.

Мәктәп китапханәсе ел дәвамында эшне план нигезендә алып бара. Уку елы башында барлык укучылар да дәреслекләр белән тәэмин ителде. Җитешмәгән дәреслекләр башка мәктәпләрдән кайтарылды, артыклары бер елга биреп торылды. Укучыларның дәреслекләр белән тәэмин ителеше – 100%. Китапханә 39 китап укучыга ярдәм күрсәтте, йөреш – 100%. Китапханәдә барлыгы 3587 китап, шуларның 2475 данәсе матур әдәбият, татарча- 1081, русча -1394, 616 данә дәреслек бар.

Укучылар һәм укытучылар - барысы да китапханәгә язылганнар. 1 нче сыйныфка килгән яңа укучыларга формулярлар ачылды. Китапханәдән алынган һәрбер китап формулярга язылып барыла. Китап биргәндә - алганда укучылар белән әңгәмәләр үткәрелде. Китапны сайларга, табарга юнәлешләр бирелде. Шулай ук укучыларга ничек китапханәдә үз – үзеңне тоту, китап уку, саклау кагыйдәләре, китапның барлыкка килүе, китап төзелеше турында китапханә дәресләре үткәрелде. “Дәреслекләргә озын гомер” дигән тема астында дәреслекләрнең сакланышы буенча рейдлар үткәрелде, “Китап докторы” акциясе кысаларында укучылар белән тузган китаплар төпләнде, дәреслекләре тышланмаган укучыларга кисәтүләр ясалды.

Юбиляр язучыларга карата китап күргәзмәләре, инценировкалар, класс сәгатьләре, уен-викториналар, уеннар оештырылды. Бу чараларның төп максаты: балаларның шушы мероприятияләр аркылы китап укыганнарын тикшерү һәм китап укуга тарту. Мәктәп буенча

үткәрелә торган фән атналыклары, олимпиадалар, мероприятияләрдә катнашкан укучыларга, укытучыларга булышлык күрсәтелде. Сәләтле балаларга аерым хезмәт күрсәү оештырылды: аларны башта барлап, сәләтләрен ачыклап, китаплар тәгьдим итү, китап эзләүдә булышлык күрсәтү. Фәнни – гамәли конференцияләрдә катнашучы укытучыларга материаллар белән ярдәм ителде. Вакытында китапларын китермәгән укучылар белән индивидуаль эш алып барылды: класс җитәкчеләре белән элемтәгә кереп, ата - анасы белән сөйләшү үткәрелде. Ата-аналар җыелышында "Мәктәп дәреслекләрен: сайлау, тәэмин итү, дәреслекләрне тоту" һ.б. темаларга чыгышлар ясалды.

Китапханәгә укучыларның йөреше канәгатьләнерлек. Укучылар китапханәдән күбрәк мәктәп программасына караган әдәбиятны алалар. Башлангыч сыйныф укучылары сыйныфтан тыш уку өчен әдәби китапларны һәм балалар өчен кызыклы китапларны теләп алалар. Әмма кечкенә сыйныфлар өчен булган басмалар бик аз, булганы да таушалган. Ә урта һәм югары сыйныф укучылары мәктәп программасында каралган төрле язучылар һәм шагыйрьләр әсәрләрен алалар, анысы да укытучылары кушканга гына. Укылыш түбән классларда әйбәтрәк.

Укытучыларга исә һәрвакыт методик ярдәм итеп торылды. Һәр кайткан китап фән укытучысына бирелде.

**<u>2021 - 2022 нче уку елында түбәндәге темаларга күргәзмәләр төзелде:</u>**

1. "Дәреслек – синең дустың, киңәшчең";
2. "Бүләк ителгән китаплар";
3. "Экстремизмга - юк!";
4. "Коррупция нәрсә ул?";
5. "Аларның тормышы безгә үрнәк";
6. "Бөтен гаилә белән укыйбыз";
7. "Муса Җәлилне искә алып" (шагыйрьнең китапларыннан күргәзмә);
8. "21 нче февраль – Халыкара Туган тел көне";
9. "Тукай - безнең горурлыгыбыз!"(шагыйрьнең китапларыннан күргәзмә);
10. "Онытылмас ул көннәр" (Бөек Җиңүнең – 77 еллыгына).

**<u>Китапханә катнашында түбәндәге масса-чаралар үткәрелде:</u>**

1. "Китапка икенче гомер бүләк ит" акциясе;
2. "Укучыларның мәдәни көндәлеге" проекты уңаеннан чара;
3. "Тормышыбыз бизәге сез!"(Өлкәннәр көненә чара);
4. "Көзге бал", Яңа ел бәйрәмнәре;
5. 8 март бәйрәменә чара;
6. "Халыкара Туган тел көне";

7. Г. Тукайга багышланган чара;
8. 9 май бәйрәме.

Яңа уку елында китапханәнең фондын даими баету өстендә эшләү, күренекле язучыларыбыз иҗатына багышланган чаралар үткәрү, укучыларыбызда китапка карата хөрмәт булдыру максат итеп куелды.

**I. КЕРЕШ ӨЛЕШ**

КИТАПХАНӘНЕҢ МАКСАТЫ:

- Уку Һәм тәрбия процессында китап укучыларны яңа информацион алымнар белән тәэмин итү.
- Укучыларда матур әдәбият укуга уңай караш һәм информацион культура тәрбияләү.
- Традицион технологияләрне үстерү, яңа технологияләрне үзләштерү һәм китап укучыларга җиткерү.

КИТАПХАНӘНЕҢ ГОМУМИ БУРЫЧЛАРЫ:

- Мәктәп китапханәсенең эшен укыту- тәрбия планына нигезләнеп укучыларга эстетик тәрбия бирү юнәлешендә оештыру.
- Укучыларның китапханәгә даими йөрүләренә ирешү.
- Укучыларда китап уку культурасы тәрбияләү.
- Укучыларда китапханә китапларына сакчыл караш тәрбияләү.

КИТАПХАНӘНЕҢ ТӨП ФУНКЦИЯЛӘРЕ:

- белем бирү;
- яңа мәгълүмат бирү;
- культуралылык тәрбияләү

КИТАПХАНӘ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ:

1. Китапханәдә барлыгы - 40 китап укучы
   1 - 4 класс - 4 укучы
   5 - 9 класс - 17 укучы
   Укытучылар - 10
   Техник хезмәткәрләр - 5
   Студентлар – 4

2. Китапханәдәге китаплар саны:
   Барлыгы - 3603 китап
   Дәреслек - 615
   Методик әдәбият - 420
   Әдәби китап - 2478
   русча - 1395
   татарча - 1083

3. Газета –журналларга язылу – 11 төрдә

## II. КИТАПХАНӘ ФОНДЫ БЕЛӘН ЭШ

| № п/п | Эш төре | Үтәү вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| **ДӘРЕСЛЕК ФОНДЫ БЕЛӘН ЭШ** | | | |
| 1 | Укучыларны тулысынча дәреслекләр белән тәэмин итү. Башка китапханәләр белән элемтәдә тору һәм дәреслекләр алып тору. | август-сентябрь | китапханәче |
| 2 | Фондны мәктәп программасына туры китереп тулыландыру<br>• Яңа уку елында укытылачак дәреслекләрнең исемлеген булдыру.<br>• Яңа кайткан дәреслекләр белән укытучыларны һәм укучыларны таныштырып бару. | даими | китапханәче |
| 3 | Китапларга заказ бирү<br>• Фән укытучылар белән бергә федераль һәм региональ исемлектәге дәреслекләргә заказ бирү. | октябрь, февраль | китапханәче |
| 4 | Дәреслекләрне электрон базага урнаштыру. | ел дәвамында | китапханәче |
| 5 | Яңа кайткан дәреслекләрне кабул итү, эшкәртү, исәпкә алу, фондка урнаштыру. | даими | китапханәче |
| 6 | “Яңа китаплар”- китап күргәзмәсен яңарту. | даими | китапханәче |
| 7 | Тузган һәм эчтәлеге буенча искергән дәреслекләрне гамәлдән чыгару. | октябрь-ноябрь, май | китапханәче |
| 8 | Дәреслекләрнең сакланышын тикшерү. | чирек саен | китапханәче |
| 9 | Укучылардан дәреслекләрне җыю һәм бирү. | май- июнь. август-сентябрь | китапханәче |
| 10 | ЭФУЛ белән эш. Кайткан дәреслекләрне ЭФУЛ га кертү. | ел дәвамында | китапханәче |
| **МАТУР ӘДӘБИЯТ ФОНДЫ БЕЛӘН ЭШ** | | | |
| 1 | Фондның торышын өйрәнү һәм аны куллануны анализлау | даими | китапханәче |
| 2 | Китапханә фондын учетта тоту. | даими | китапханәче |
| 3 | Бүләк ителгән китапларны кабул итү, эшкәртү һәм учетка алу. | даими | китапханәче |
| 4 | Фондтагы китапларны эстетик яктан матур булырлык итеп тезү, алфавит буенча тезелүен гел тикшереп тору. | даими | китапханәче |
| 5 | Китапларны укучы үзе алып укырлык итеп урнаштыру | даими | китапханәче |
| 6 | Фондтагы китапларның тотылышын тикшереп тору:<br>• Аеруча кыйммәтле басмаларны даими рәвештә сакланышын тикшерү.<br>• Систематик рәвештә укырга бирелгән китапларның кире кайтарылуын контрольдә тоту.<br>• Югалган китапларны барлау, вакытында чарасын күрү, урынына икенчесен алу.<br>• Таушалган китапларны ремонтлауны оештыру.<br>• Фондтагы китапларны саклау һәм тиешле режимда тотуны оештыру. | даими | китапханәче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | Накладнойларны вакытында эшкәртү, тиешле урынга тапшыру. | даими | китапханәче |
| 8 | Инвентаризация үткәрү. | май | китапханәче |
| 9 | Укучыларга укырга киңәш ителгән китаплар исемлеген төзү. | октябрь | китапханәче |
| **МАТБУГАТ ФОНДЫН ТУПЛАУ** | | | |
| 1 | Беренче һәм икенче яртыеллык матбугатка язылуны оештыру. | октябрь, апрель | китапханәче |
| 2 | Килгән газет-журналларны вакытында теркәү. | даими | китапханәче |
| 3 | Китапханәгә килә торган газет-журналларны бергәләп уку, әңгәмәләр үткәрү. | даими | китапханәче |
| **КИТАП УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ЭШ. ИНДИВИДУАЛЬ ЭШ** | | | |
| 1 | Кулланучыларны китапханә кагыйдәләре, тәртип, китаплар һәм фондның урнашуы белән таныштыру. | сентябрь | китапханәче |
| 2 | Яшь үзенчәлегенә карап матур әдәби китап уку культурасы тәрбияләү. Китапны мөстәкыйль сайлый белергә өйрәтү. | даими | китапханәче |
| 3 | Китапны тапшырганда укыган әсәрләр турында әңгәмә үткәрү. | даими | китапханәче |
| 4 | Китапханәгә яңа кайткан китаплар белән таныштыру. | яңа китаплар кайткач | китапханәче |
| 5 | “Укучыларның мәдәни көндәлеге” проекты уңаеннан чара үткәрү. | сентябрь | китапханәче, баш.сыйныф укытучылары |
| 6 | Укучыларнын формулярлары белән эшләү. Китапны вакытында тапшырмаган укучылар белән эшләү. | айга бер тапкыр | китапханәче |
| 7 | 1 сыйныф укучыларын мәктәп китапханәсе белән таныштыру. Формулярлар ачу. | сентябрь | китапханәче |
| 8 | Укыган әсәрләргә анализ ясау. | ярты елга бер | |
| 9 | Китап, газет- журналлар белән кызыксынмаучы укучылар белән әнгәмә. | даими | китапханәче |
| 10 | “Китапка икенче гомер бүләк ит” акциясен уздыру. | август - октябрь | китапханәче |
| 11 | “Бүләк ителгән китаплар” исемле китап күргәзмәсе оештыру. | сентябрь, октябрь | китапханәче |
| 12 | Тәнәфес вакытларында, класс сәгатьләрендә китап-журналларга телдән реклама ясау. | даими | китапханәче |
| 13 | Җәйге ялда укылырга тиешле китаплар исемлеген төзү һәм укучыларны таныштыру. | май | әдәбият укытучысы, китапханәче |
| **УКЫТУЧЫЛАР КОЛЛЕКТИВЫНДА ЭШ** | | | |
| 1 | Укытучыларны яңа кайткан методик китаплар, әдәбиятлар, газет- журналлар белән вакытында таныштыру, тәкъдим итү. | ел дәвамында | китапханәче |
| 2 | Педсоветларда яңалыклар белән таныштыру | чиреккә бер тапкыр | китапханәче |
| 3 | Бәйрәмнәр, истәлекле даталар буенча материаллар туплап, укытучыларга тәкъдим итү. | ел дәвамында | китапханәче |
| 4 | Язучыларның юбилейларына багышлап “Юбилярлар” дигән стендны яңартып тору. | ел дәвамында | китапханәче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **КИТАПХАНӘ АКТИВЫ БЕЛӘН ЭШ** | | | |
| 1 | Китапханә активы булдыру. | сентябрь | китапханәче |
| 2 | Дәреслекләрнең тотылышын тикшерү рейдлары үткәрү. | айга бер тапкыр | китапханә активы, дежурлар |
| 3 | Китапханәдә тәртип урнаштыру, тузган китапларны ремонтлау, газет-журналларны теркәү. | сентярь-май | китапханә активы, |
| 4 | Мероприятияләрне китапханә активлары белән берлектә әзерләү. | ел дәвамында | китапханә активлары, китапханәче |
| **АТА-АНАЛАР БЕЛӘН ЭШ** | | | |
| 1 | Газет-жуналлардан алынган материалларны туплау. | ел дәвамында | китапханә активы, китапханәче |
| 2 | "Мәктәп дәреслекләрен: сайлау, тәэмин итү, дәреслекләрне тоту" (әти-әниләр җыелышында чыгыш) | ноябрь | китапханәче |
| 3 | "Бөтен гаилә белән укыйбыз" - балалар өчен тәкъдим ителгән китаплар күргәзмәсен оештыру. | ел дәвамында | китапханә активы, китапханәче |
| 4 | "Гаилә укулары" үткәрү. | чиреккә бер тапкыр | китапханәче |
| 5 | Ата- аналарны балаларының китап укулары белән таныштыру (әти-әниләр җыелышында чыгыш). | гыйнвар | китапханәче |
| **МАССА – КҮЛӘМ ЭШ** | | | |
| 1 | Белем бәйрәмендә катнашу. | сентябрь | китапханәче |
| 2 | Көзге бал, яңа ел бәйрәмнәренә әзерлек эше алып бару. Материаллар туплау. | октябрь, декабрь | китапханәче |
| 3 | Китап күргәзмәсе. "22 нче октябрь – мәктәп китапханәсе көне" | 24 октябрь | китапханәче |
| 4 | "Нинди китап укысаң-шундый кеше булырсың", башлангыч сыйныф укучылары белән әнгәмә. | гыйнвар | китапханәче |
| 5 | "Синең яраткан китабың"- башлангыч һәм урта класс укучылары арасында анкета үткәрү. | февраль | китапханәче |
| 6 | Фән атналыкларында китап күргәзмәсе. | даими | китапханәче |
| 7 | Юбилярлар һәм истәлекле даталар уңаеннан китап күргәзмәсе, төрле чаралар оештыру. (викторина, әңгәмә, плакат- күргәзмә, кичә) | ел дәвамында | китапханәче |
| 8 | Авыл китапханәсе белән берлектә эш. Китапханә дәресләре үткәрү. | ел дәвамында | китапханәче |
| 9 | 27 май - китапханәчеләр көне. | май | китапханәче |
| **ХЕЗМӘТ ТӘРБИЯСЕ ҺӘМ ПРОФОРИЕНТАЦИЯ БИРҮ** | | | |
| 1 | Китапханәдә төрле һөнәрләргә багышланган китапларны, материалларны тулыландыру. | даими | китапханәче |
| 2 | "Барлык һөнәр дә мактаулы" дигән темага китап күргәзмәсе оештыру. | март | китапханәче |
| 3 | Имтихан бирүчеләрне кирәкле китаплар белән тәэмин итү. | ел дәвамында | китапханәче, предмет ияләре |
| **ХОКУК ТӘРБИЯСЕ** | | | |
| 1 | Китап күргәзмәсе: "Экстремизмга - юк!" | сентябрь | китапханәче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Хокук бозуны кисәтүләргә каршы кирәкле мәгълүматләр белән укучыларны тәэмин итү. | даими | китапханәче |
| 3 | “Коррупциягә юк дип әйт!” темасына мәкаләләр туплау, китап күргәзмәсе. | декабрь | китапханәче |
| **ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ** | | | |
| 1 | Өлкәннәр көненә карата чара үткәрү. | 1 октябрь | кл.җит., китапханәче |
| 2 | Хәтер көненә карата китап күргәзмәсе -“Гел хәтердә, гел истә”. | 15 октябрь | тарих укыт, китапханәче |
| 3 | М.Җәлилнең туган көнен билгеләп үтү. | 15 февраль | туган тел укытучылары, китапханәче |
| 4 | “Халыкара Туган тел көне” уңаеннан әдәби чара, китап күргәзмәсе. | 21 февраль | туган тел укытучылары, китапханәче |
| 5 | “Ватанны саклаучылар көне”- чара үткәрү, китап күргәзмәсе. | Февраль | китапханәче |
| 6 | “Беркем дә, беркайчан да онытылмый”- классларда әңгәмәләр оештыру. | даими | кл. җит., китапханәче |
| **ӘХЛАК ТӘРБИЯСЕ** | | | |
| 1 | “Ялгыш язмышлар” 9 кл. әнгәмә. | декабрь | китапханәче |
| 2 | “Сәламәт тәндә сәламәт акыл”, “Сак булыйк-наркомания”, “СПИД –XXI гасыр әфәте” . | декабрь, май | китапханәче |
| **ЭКОЛОГИК ТӘРБИЯ** | | | |
| 1 | Кошлар көнен билгеләп үтү. | апрель | биология укытучысы, китапханәче |
| **ПРОФЕССИОНАЛЬ ҮСЕШ** | | | |
| 1 | Мәктәп китапханәчеләренең район семинарында катнашу. | график буенча | китапханәче |
| 2 | Конкурсларда катнашу. | даими | китапханәче |
| 3 | ҮЗБЕЛЕМ:<br>- китапханә эше турында приказлар, хатлар, инструкцияләр белән танышып бару. | ел дәвамында | китапханәче |
| 4 | Иң яхшылардан саналган мәктәп китапханәчеләренең тәҗрибәләрен кулланып үз белемеңне күтәрү өстендә эшләү. | даими | китапханәче |
| 5 | Курсларда булып квалификацияне күтәрү. | 3 елга бер | китапханәче |
| 6 | Яңа китапханә технологияләрен үзләштерү һәм традицион технологияләрне камилләштерү. | даими | китапханәче |